## *“Урындагы башлангычларга ярдәм”*

# “Яшәсен ППМИ!”

**2016 елда Башкортстанда “Урындагы башлангычларга ярдәм” программасы (ППМИ) эшли башлады. Беренче елда, гадәттәгечә, бу программага сагаеп карадылар, җитди мөнәсәбәттә булмадылар. Ләкин конкурска җитди караган һәм җиңгән башка авыл Советлары тәҗрибәсе безнең Ялгызкаен авыл биләмәсен дә алга өндәде. Инде 2017 елдан бирле без дә әлеге программада катнашабыз.**

2017 елда – “МТЗ-82” тракторын, киләсе елга инде конкурста җиңеп, трактор өчен җиһазларның тулы комплектын сатып алдык (фронталь төягеч, кар чистарту роторы, трактор прицепы).

2019 елда гомум җыелыш карары белән безнең авыл мәдәният йорты өчен заманча җиһазлар сатып алдык һәм “Бердәм Русия”нең “Эшлекле гамәлләр” программасы буенча район хакимияте һәм республика 1,5 миллион сумга яңа җиһазлар өчен материаллар сатып алуга акча бүлде. Әлеге акча һәм эшкуарларыбыз, авыл халкы ярдәме белән Ялгызкаен авылы мәдәният йорты эчендә косметик ремонт үткәрдек һәм яңа җиһазлар урнаштырдык.

Халыкның тормыш-көнкүреше яхшыру белән авылда проблемалар кимеми. Халыкның таләпләре кар түгәрәге кебек үсә. Бу дөрес тә – һәркем уңайлы шартларда яшәргә тели, һава торышы нинди булуга карамастан, яхшы юллар булсын, газ һәм яктылык даими янсын. Шуңа күрә 2020 елда без тагын бер трактор сатып алдык, ул юлларны тәртиптә тоту өчен заманча көрәк белән җиһазландырылган.

2010 елда кертелгән суүткәргечләр челтәре даими хезмәтләндерүне, шулай ук авылыбызның шәхси торак төзелеше барган яңа бистәләренә кадәр киңәйтүне таләп итә. Бу максатлар өчен Красноусолдан яисә Стәрлетамак шәһәреннән экскаватор чакырту арзан түгел. Шуңа күрә 2021 елда гомум җыелыш карары нигезендә, инициатив төркемнең яхшы эшләве, халыкның һәм безнең эшкуарларның ярдәме белән без яңа трактор өчен тагын бер погрузчик сатып алдык. Иң мөһиме – бу экскаватор авыл биләмәсендәге бик күп мөһим проблемаларны үз көчебез белән хәл итәргә мөмкинлек бирә.



Чираттагы иң актуаль проблема дип Ялгызкаен урта мәктәбенең тәрәзә блокларын һәм ишекләрен алмаштыру билгеләнде. Уку йорты Үтәк, Буруновка, Тугай авыл биләмәләре өчен дә төп мәктәп булып тора, анда 200 бала укый.

Мәктәп 1984 елда төзелгән һәм файдалануга тапшырылган, 40 ел дәвамында аңа бер тапкыр да капиталь ремонт үткәрелмәде. Агымдагы ремонт, нигездә, косметик эшләр, бюджетның аз-маз акчасы, иганәчеләр ярдәме, эшкуарлар һәм ата-аналар исәбенә башкарылды.

Былтыр “Урындагы башлангычларга ярдәм” программасы ярдәмендә һәм инициатив төркем тырышлыгы белән Ялгызкаен урта мәктәбенә тәрәзә блоклары һәм ишекләр сатып алынды һәм урнаштырылды. Бу программа ярдәмендә балаларыбыз уңайлы шартларда укый.


Тагын бер тапкыр авылдашларыбыз исеменнән Башкортстан Республикасы Хөкүмәтенә, Гафури районы хакимиятенә безнең инициатив төркем эшен югары бәяләгәне өчен зур рәхмәтебезне белдерәбез.

Хәзер инде яңа инициатив төркем булдырылды, ул “ППМИ-2023” проблемалары белән шөгыльләнәчәк. Ноябрь башыннан Р. Насыйрова, З. Вәлишина составындагы инициатив төркем авыл биләмәсе халкы белән актив эш алып бара. Башлангыч җыелышлар, анкета тутыру һәм халыктан сораштыру нәтиҗәләре буенча безнең авыл биләмәсенең иң актуаль проблемалары ачыкланды: Ялгызкаен авылының Әсфәндияров урамына асфальт җәю, мәдәният йортының түбәсен һәм бинасын капиталь ремонтлау, үзәк чокыр аша күперне төзекләндерү.

Авыл биләмәсе хакимияте һәм эшкуарлар да шундый ук фикергә килделәр, чөнки безнең авыл биләмәсендә яшәүчеләр саны арта, шул исәптән, Аллаһка шөкер, яшь һәм күпбалалы гаиләләр дә аз түгел. Бүген андыйлар – 19. Һәр гаиләдә автомобиль бар, ә кайбер ихаталарда икешәр, хәтта өчәр. Көн саен каядыр баралар. Бигрәк тә җәйге чорда Әсфәндияров, Социалистик, Совет, Урал урамнарына йөкләнеш зур. Аллаһка шөкер, Совет һәм Урал урамнары асфальтланган, ә Әсфәндияров һәм Социалистик урамнарында җәен тәүлек буе тузан туза. Халык зарлана, юлны бозарга, ясалма каршылыклар ясарга мәҗбүр, бу автомобиль йөртүчеләр белән бәхәсле хәлләргә китерә. Шуңа күрә без мәктәп, балалар бакчасы, мәдәният йорты, хакимият, балалар өчен уен һәм спорт мәйданы урнашкан Әсфәндияров урамына асфальт җәяргә карар кылдык. Урамның озынлыгы – 900 метр. Безнең исәпләүләр буенча, эшләр ким дигәндә 3 миллион сумга басачак.

Шушы уңайдан 30 декабрьдә мәдәният йорты бинасында җыелыш үтте. Халык шушы башлангычны бертавыштан хуплады.

**Гаян ФӘЕЗОВ.**
Гафури районы.



**2017 елда “Урындагы башлангычларга ярдәм” программасында катнашып, безнең авыл хакимияте Үтәк авылында балалар мәйданчыгы төзетүгә иреште. Аннан соңгы елларда авыл мәдәният йортының тәрәзәләре алмаштырылды, чаршаулар, музыкаль аппаратура алынды. Тугай авылы клубының ишеге һәм тәрәзәләре өлешләтә яңартылды, бильярд уены, концерт өчен кирәкле җиһазлар алынды.**

# “Раритет”ны яңага алыштырачакбыз!

Бу елга да өметләребез зур. Авыл хакимиятенә караучы барлык авылларда да җыелышлар уздырдык, халыкның теләк-фикерләрен исәпкә алып, бердәм фикергә килдек: безгә янгын сүндерү машинасы кирәк! Бурдан кала, уттан калмый, дип юкка әйтмәгәннәр бит. Соңгы ун елда авылларыбызда булган янгыннар – шуңа дәлил. Әле кулланган машинабыз “Мамай заманы”ннан калган дисәк тә буладыр – 40 ел элек алынган, өстәвенә, безгә кадәр дә кулланылышта булган, адым саен зур ремонт таләп иткән “раритет”. Янгын депосында хезмәт салган егетләребезнең тырышлыгы белән генә йөреп ята ул.

“ППМИ-2023”тә без “УАЗ-330365” шассие нигезендәге “МПК-08” мобиль янгын сүндерү комплексы алу өчен тавыш бирдек. Кирәкле 2 миллион 500 мең сумның 1 миллион 200 меңе – республика субсидиясе, район бюджетыннан – 1 миллион 20 мең, авыл халкыннан – 130 мең, урындагы крестьян хуҗалыкларыннан – 150 мең сум җыю күзаллана. Программада җиңеп чыгарбыз дип ышанабыз.

**Равил РАКАЕВ.**

__P.S.__ *Мәкалә басмага әзерләнгәндә шундый шатлыклы хәбәр килеп ирешә: Гафури районының Үтәк авылы хакимияте “Яраткан авылыма – сәламәт балалар” проектында җиңеп, Президент Грантына лаек булды. Мәдәният йорты янында воркаутлы яңа балалар мәйданчыгы төзеләчәк. Афәрин, үтәклеләр!*

# Тәрәзәләр балкып торачак!



**Республика халкы арасында “Урындагы башлангычларга ярдәм” программасы бик популяр. Безнең Татар-Олкан авыл биләмәсе дә 2017 елдан шушы конкурста катнаша. Ул елда без әлеге бәйгедә авылның Мичурин урамына 600 мең сумга ком-таш түшәү проблемасы белән катнаштык һәм конкурста җиңдек. Мичурин урамында яшәүчеләр бик канәгать калды!**

2018 елда янгын сүндерү машинасы сатып алырга ниятләдек һәм ул бәйгедә дә җиңдек. 1 миллион 135 мең сумга “УАЗ” базасында янгын сүндерү машинасы сатып алдык.

2019 елда авыл биләмәсенә кергән Югары Сәрдек авылы мәктәп-балалар бакчасы өчен уен җиһазлары элементлары белән күләгәле түбә сатып алуда катнаштык. Ул 300 мең сумлык булды. Әлеге җиһаз мәктәпбалалар бакчасы территориясендә урнаштырылды.

2021 елда да конкурс сайлап алуларын уңышлы уздык. Югары Сәрдек авылындагы Яшел урамга ком-таш түшәлде.

Программада быел да катнашабыз һәм 1 миллион 996 мең сумга Татар-Олкан авылы урта мәктәбе бинасында тәрәзә конструкцияләрен алыштыру һәм урнаштыру проектын сайлап алдык.

Башлангыч җыелышлар, төрле спорт һәм мәдәни чаралар, укучылар арасында рәсемнәр бәйгесе, авыл халкы арасында анкеталаштыру үткәрелде. Шулай ук, былтыр 24 декабрьдә йомгаклау җыелышы үтте. Анда авыл халкы әлеге проектны сайлады. Киләчәктә балалар якты, җылы мәктәптә белем алыр, дип ышанысы килә.

**Гүзәл ЯКУПОВА.**
Туймазы районы.

*Фотолар авыл хакимиятләре сайтларыннан алынды.*